| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.10.2021 г.Казань № 741

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 11 октяберендә 7966 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында» 2021 елның 10 октябрендәге 967 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләүнең кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
10 октябрендәге 741 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның
10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян
күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында» 2021 елның 10 октябрендәге 967 номерлы карары белән билгеләнгән бер тапкыр матди ярдәм (алга таба – бер тапкыр матди ярдәм) билгеләү һәм түләү механизмын билгели.

2. Бер тапкыр матди ярдәм түләнә торган затлар:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) затларның гаилә әгзаларына (хатынына (иренә), балаларына, ата-анасына (законлы вәкилләренә) һәм һәлак булган затның иждивениесендә торган затларга) (алга таба – һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзасы) L-410 самолеты юлыккан һәлакәт), – һәлак булган (үлгән) затның һәр гаилә әгъзасына тигез өлешләрдә 1,0 млн.сум күләмендә;

L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегенә авыр һәм уртача дәрәҗәдә зыян килгән гражданнарга – бер кешегә 400,0 мең сум күләмендә, L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегенә җиңелчә зыян килгән гражданнарга – бер кешегә 100,0 мең сум (алга таба – сәламәтлегенә зыян килгән гражданин).

3. Бер тапкыр матди ярдәмне түләү турындагы гариза яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль райондагы (шәһәр округындагы) бүлегенә (Идарәгә) (алга таба – социаль яклау органы) шәхсән яки почта элемтәсе ярдәмендә бирелә.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук әлеге белешмәләрне үз эченә алган документларның чын булуы өчен җаваплы була.

Гражданин һәлак булган (үлгән) очракта, гариза һәлак булган (үлгән) затның һәр гаилә әгъзасы яки аларның законлы вәкиле (вәкилләре) (вәкаләтле зат (затлар)) тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган документларның күчермәләрен күрсәтеп тапшырыла.

4. Һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзасы яисә аның законлы вәкиле (аның тарафтан вәкаләт бирелгән зат) бер тапкыр матди ярдәм түләү турындагы гаризаны әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы формада тапшыра.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

аны алу хокукына ия булган башка гаилә әгъзасы файдасына (булган очракта), бер тапкыр матди ярдәм алудан баш тарту турында гариза;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гаилә әгъзалары исәбеннән һәлак булган затның гаилә әгъзасы исеменә кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитлары белән документ күчермәсе;

һәлак булучылар белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документларның күчермәләре;

Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәсе, әгәр гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылса;

һәлак булган (үлгән) зат иждивениесендә тору фактын раслый торган документларның күчермәләре, һәлак булган (үлгән) зат иждивениесендә торган очракта.

Һәлак булган (вафат булган) затның гаилә әгъзасы гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне раслый торган документны күрсәтә.

5. Сәламәтлегенә зыян килгән гражданин яисә аның законлы вәкиле (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат) әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча бер тапкыр матди ярдәм түләү турында гариза тапшыра.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

сәламәтлегенә зыян килгән гражданин исеменә кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитлары белән документ күчермәсе;

сәламәтлегенә килгән зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтеп, суд-медицина экспертизасы бәяләмәсе күчермәсе;

Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсе, әгәр гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылса.

Сәламәтлегенә зыян килгән гражданин, гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне раслый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр документ оригиналын биргән орган (учреждение) тарафыннан нотариаль рәвештә таныкланмаган булса, оригиналларын күрсәтеп бер нөсхәдә тапшырыла һәм социаль яклау органы хезмәткәре тарафыннан таныклана. Әлеге Тәртип нигезендә тапшырыла торган документларның төп нөсхәләре тиешенчә рәсмиләштерелергә, шул исәптән өстәп язылган, сызылган сүзләре һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтмәләре булмаска тиеш.

Гариза һәм гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре социаль яклау органына почта буенча җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре, паспорт күчермәсен яки шәхесне раслаучы башка документ күчермәләреннән тыш, документның оригиналын биргән орган (учреждение) тарафыннан яки нотариус аша расланган булырга тиеш.

7. Гаризаны гаризаларны теркәү журналында теркәү гариза социаль яклау органына алынган көнне гамәлгә ашырыла, әгәр гаризага әлеге Тәртипнең 4-5 пунктлары нигезендә документларның барлык күчермәләре дә теркәлгән булса.

Социаль яклау органы гариза белән документларны кирәкле барлык документлары да булу һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве предметы (тиешенчә рәсмиләштерү, документларның күчермәләрендә чистартылган, өстәп язылган, сызылган сүзләре һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтүләре булмавы) буенча тикшерә.

8. Әгәр гариза һәм аңа теркәлгән документлар әлеге Тәртипнең 4-5 пунктларындагы таләпләргә җавап бирмәсә, социаль яклау органы хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итүдән баш тарту нигезләре булуы турында телдән хәбәр итә һәм, гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, гаризаны кайтарып бирә (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә). Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча гаризаны кабул итүдән баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә. Документларның таныкланган күчермәләре теркәлгән гаризаны почта аша (электрон почта буенча) алган очракта, социаль яклау органы хезмәткәре гаризаны теркәгән датадан башлап биш эш көне эчендә теркәлгән документларның күчермәләре белән гаризаны кабул итүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә язмача белдерү җибәрә.

9. Гариза һәм аңа теркәлгән документларның күчермәләре әлеге Тәртипнең 4-5 пунктларындагы таләпләргә туры килгән очракта, социаль яклау органы ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон рәвештә дә, вәкаләтле органнардан түбәндәгеләр өчен кирәкле булган киләсе белешмәләрне соратып ала:

1) Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгәннәр исәбеннән һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзасына бер тапкыр матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен:

һәлак булган (үлгән) затның вафат булуы турында;

һәлак булган (үлгән) затның баласы (балалары) тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәвенә алу турында;

һәлак булган (үлгән) затның тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәвенә алу турында;

һәлак булган (үлгән) зат белән өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында;[1]

L-410 самолеты юлыккан һәлакәт факты буенча җинаять эше нигезендә һәлак булган (үлгән) гаилә әгъзасын зыян күрүче дип тану турында карар буенча;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында белешмәләр, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында белешмәләр;

---

[1] Опека (попечительлек) билгеләнгән очракта тапшырыла.

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яки хокукка сәләтсез дип танылуы турында.

2) Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар исәбендәге, сәламәтлегенә зыян килгән гражданинга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен:

L-410 самолеты юлыккан һәлакәт факты буенча җинаять эше нигезендә гражданинны сәламәтлегенә зыян килгән дип тану турында;

ундүрт яшенә җитмәгән, сәламәтлегенә зыян килгән, балигълык яшенә җитмәгән баланың тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәвенә алу турында;

сәламәтлегенә зыян килгән гражданинга карата опека (попечительлек) билгеләнүе турында;[2]

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукында чикләнүне гамәлдән чыгару турында белешмәләр, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда ундүрт яшенә җитмәгән, сәламәтлегенә зыян килгән, балигълык яшенә җитмәгән гражданинны йолып алу турында белешмәләр;

сәламәтлегенә зыян килгән, ундүрт яшенә җитмәгән балигъ булмаган гражданинның, ата-анасының яки мондый баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләтен чикләү яки хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

Россия Федерациясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданинының яшәгән яки торган урыны буенча теркәлгән яки теркәлмәгән булуы турында.

Мөрәҗәгать итүче социаль яклау органына әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

10. Һәлак булган (үлгән) затның бер һәм икедән артык гаилә әгъзасы булган очракта, бер тапкыр матди ярдәм һәлак булган (үлгән) затның һәр гаилә әгъзасына әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзасына бер тапкыр матди ярдәм күләменнән тигез өлешләр белән бирелә.

Бер тапкыр матди ярдәмнең бер өлешен алуга хокукы булган гаилә әгъзасы, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасындагы форма буенча социаль яклау органына гариза тапшыру юлы белән, бер тапкыр матди ярдәм алу хокукына ия булган затлар исәбендәге башка гаилә әгъзасы файдасына аны алудан баш тартырга мөмкин.

Һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзалары арасында һәлак булган (үлгән) затның аерым гаилә әгъзаларында бер тапкыр матди ярдәм алуга хокук булуына (булмавына) бәйле мәсьәләләрдә каршылыклар булган очракларда, һәлак булган (үлгән) затның гаилә әгъзасы (гаилә әгъзалары) социаль яклау органына яки Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) мондый каршылыклар булуы турында язмача хәбәр җиткерә(ләр). Министрлык һәлак булган затның гаилә әгъзасыннан (гаилә әгъзаларыннан) каршылыклар булуы турында язмача хәбәр

---

[2] Опека (попечительлек) билгеләнгән очракта тапшырыла.

алынган көннән соң соңгы икенче көннән дә соңга калмыйча бер тапкыр матди ярдәм билгеләү турында карар кабул итүне туктатып тора.

Һәлак булган затның (затларның) гаилә әгъзалары арасында мондый каршылыклар тулысынча җайга салынгач һәм бер тапкыр матди ярдәмне алучы зат (затлар) ачыклангannan соң, һәлак булган (үлгән) затның каршылыклар булуы турында язмача хәбәр иткән гаилә әгъзасы (гаилә әгъзалары) тарафыннан каршылыкларны җайга салу һәм бер тапкыр матди ярдәм алучыны (алучыларны) билгеләү турында раслый торган документ тапшырылган яки һәлак булган (үлгән) затның каршылыклар булуы турында язмача хәбәр иткән гаилә әгъзасы (гаилә әгъзалары) гаризасын (гаризаларын) кире алган көннән башлап киләсе көн узып киткәнче бер тапкыр матди ярдәм билгеләү эше торгызыла.

11. Гариза һәм аңа теркәлгән документларның күчермәләре әлеге Тәртипнең 4-5 пунктларындагы таләпләргә җавап бирсә, һәм социаль яклау органы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада, әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә вәкаләтле органнардан алынган белешмәләр әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы таләпләргә туры килсә, социаль яклау органы хезмәткәре гаризаны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда гаризаны һәм аңа теркәлгән документларның күчермәләрен һәм белешмәләрне Министрлыкка җибәрә.

12. Социаль яклау органы гаризаны кирәкле барлык документларның күчермәләре белән тапшырган көннән башлап 10 эш көне эчендә бер тапкыр матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итә һәм бер тапкыр матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көне эчендә бер тапкыр матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр җиткерә.

Карар кабул ителгәннән соң, ләкин әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә бер тапкыр матди ярдәм алучылар исемлеге (исемлекләре) төзелгән көннән дә соңга калмыйча, һәлак булган затның (затларның) гаилә әгъзасыннан (гаилә әгъзаларыннан) һәлак булган затның (затларның) гаилә әгъзалары арасында бер тапкыр матди ярдәм алу хокукы булуына (булмавына) бәйле мәсьәләләрдә каршылыклар булуы турында язмача мөрәҗәгать алынса, Министрлык, мондый мөрәҗәгать алынган көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, бер тапкыр матди ярдәм түләүне туктатып тора. Һәлак булган затның (затларның) каршылыклар булуы турында язмача хәбәр иткән гаилә әгъзасы (гаилә әгъзалары) каршылыкларны җайга салу һәм бер тапкыр матди ярдәм алучыны (алучыларны) билгеләү турында раслый торган документны тапшырган яисә һәлак булган затның (затларның) гаилә әгъзасы (гаилә әгъзалары) каршылыклар булуы турындагы гаризаны (гаризаларны) кире алган көннән соң икенче көннән соңга калмыйча бер тапкыр матди ярдәм түләү эше яңартып җибәрелә.

Бер тапкыр матди ярдәм һәлак булган затның (затларның) гаилә әгъзаларына мондый каршылыклар 2021 елның 1 декабренә кадәр тулысынча җайга салынып беткән очракта һәм бер тапкыр матди ярдәм алучы (алучылар) билгеләнгәннән соң законнарда билгеләнгән тәртиптә түләнә.

13. Бер тапкыр матди ярдәм, аны сорап, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт көненнән башлап алты ай узганчы мөрәҗәгать иткән очракта билгеләнә.

14. Министрлык бер тапкыр матди ярдәм билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек срокта бер тапкыр матди ярдәм алучыларның исемлекләрен төзи һәм финанслау өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гариза җибәрә.

15. Бер тапкыр матди ярдәм суммаларын аны алучыларның кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерү Министрлык тарафыннан бер тапкыр матди ярдәмне түләү өчен Министрлыкка акча килгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

16. Министрлык бер тапкыр матди ярдәмнең соңгысын түләп бетергән көннән башлап бер айлык срокта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 4 нче кушымтадагы форма буенча Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
_______________________________________ социаль
муниципаль районында (шәһәр округында)
яклау бүлегенә (идарәсенә)
кемнән ___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
_____________________________________________
(теркәлгән адресы)
паспорты: сериясе ___________ № _____________
кем тарафыннан бирелгән ____________________
бирү датасы ______________________________

ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган ______________________________________________________ өчен
(һәлак булган (үлгән) затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
миңа бер тапкыр матди ярдәм түләвегез турында үтенәм.

Һәлак булган затның бер тапкыр матди ярдәм алу хокукына ия булган гаилә әгъзалары турында мәгълүмат җиткерәм:

| Т/с | Гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | Туган көне, ае, елы | Туганлык дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Һәлак булган зат өчен бер тапкыр матди ярдәм алуга хокукы булган башка гаилә әгъзалары, шул исәптән һәлак булган зат иждивениесендә торган башка затлар юк.

_______________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Бер тапкыр матди ярдәм түләү өчен түбәндәге документларны тапшырам:

| Т/с | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Аны алу хокукына ия булган башка гаилә әгъзасы файдасына (булган очракта) бер тапкыр матди ярдәм алудан баш тарту турында гариза | |
| 2 | Һәлак булган зат иждивениесендә тору фактын раслый торган документларның күчермәләре, һәлак булган зат иждивениесендә торган очракта. | |
| 3 | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибенең 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гаилә әгъзалары исеменә кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитлары белән документ күчермәсе | |
| 4 | Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсе, әгәр гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылса | |
| 5 | Башка документлар | |

Бер тапкыр матди ярдәмне әлеге кредит учреждениесенә күчерү турында сорыйм: ________________________________________________

(атамасы)

Кредит учреждениесенең банк реквизитлары:
Ярдәм алучы зат банкы

__________________________________________

(атамасы)

Ярдәм алучы зат банкының ИНН/КПП

____________________________________________

Исәп-хисап счеты ____________________________

Кор. счет ________________________________________

Банкның БИК __________________________________

Ярдәм алучы затның Ф.И.А.

_________________________________________________

Ярдәм алучы затның шәхси тәңгәллек саны

_________________________________________________

Паспорты _____________________________________

Шәхси счеты ___________________________________

Элемтә өчен телефон номеры _________________________________

Тапшырылган белешмәләрнең дөрес, шулай ук документларның чын булуын раслыйм.

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматларымны җыю, эшкәртү (шул исәптән персональ мәгълүматларны автоматлаштырып эшкәртү), саклау һәм минем персональ мәгълүматларымны

мәгълүмат алмашу системасында өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм

____________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

«___» __________ 20__ ел ____________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

---

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

______________________________ социаль
муниципаль районында (шәһәр округында)
яклау бүлегенә (идарәсенә)
кемнән ________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

________________________________________________
(теркәлгән адресы)

________________________________________________
паспорты: сериясе __________ № _______________
кем тарафыннан бирелгән ____________________
бирү датасы ____________________________

## ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегемә __________________________________________ дәрәҗәдә зыян килгән кеше буларак,
(сәламәтлеккә килгән зыян дәрәҗәсе күрсәтелә)
миңа бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүегезне сорыйм.

Бер тапкыр матди ярдәм түләү өчен түбәндәге документларны тапшырам:

| Т/с | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданин исеменә кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитлары белән документ күчермәсе | |
| 2. | Сәламәтлеккә килгән зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтеп, суд-медицина экспертизасы бәяләмәсе күчермәсе | |
| 3. | Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәсе, әгәр гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылса | |

Бер тапкыр матди ярдәмне әлеге кредит учреждениесенә күчерү турында сорыйм: ______________________________________________
(атамасы)

Кредит учреждениесенең банк реквизитлары:
Ярдәм алучы зат банкы

______________________________________________
(атамасы)

Ярдәм алучы зат банкының ИНН/КПП

_________________________________________________________

Исәп-хисап счеты

_________________________________________________________

Кор. счеты ____________________________________________
Банкның БИК __________________________________
Ярдәм алучының Ф.И.А.

_________________________________________________________

Ярдәм алучының шәхси тәңгәллек саны

_________________________________________________________

Паспорты

_________________________________________________________

Шәхси счет ____________________________________
Элемтә өчен телефон номеры ______________________________________

Тапшырылган белешмәләрнең дөрес, шулай ук документларның чын булуын раслыйм.

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматларымны җыю, эшкәртү (шул исәптән персональ мәгълүматларны автоматлаштырып эшкәртү), саклау һәм минем персональ мәгълүматларымны мәгълүмат алмашу системасында өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм

___________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

«___» __________ 20__ ел ______________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

__________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

социаль яклау бүлегенә (идарәсенә)
кемнән _______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

________________________________________________
(теркәлгән адресы)

________________________________________________
паспорт: сериясе ________ № _________________
кем тарафыннан бирелгән ____________________
бирү датасы _______________________________

## Бер тапкыр матди ярдәм алудан аны алу хокукына ия булган башка гаилә әгъзасы файдасына баш тарту турында ГАРИЗА

Мин, ______________________________________________________________,
(бер тапкыр матди ярдәмнән баш тартучы гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туганлык дәрәҗәсе)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган__________
______________________________________________________ гаилә әгъзасы булып торам,
(һәлак булган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

____________________________________________________________________файдасына
(гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), һәлак булган затка карата туганлык дәрәҗәсе)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган затка бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүдән баш тартам.

«____» ________20____ ел. __________________________________________________
(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында 2021 елның 10 октябрендә L-410 самолеты юлыккан һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү өчен 20___ елның ___________________ Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап

| Т/с | Түләүнең атамасы | Түләү күләме (мең сум) | Түләү билгеләнгән гражданнар саны | Түләү суммасы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| Барлыгы | | | | |

Җитәкче ___________ / ______________________
(имза) (тулы имза)
Баш бухгалтер ___________ / ______________________
(имза) (тулы имза)